**Бәхәсле балалар.**

Иң мөһим булып һәрбер кешенең тормышында кешеләр белән аралашу (үзара бәйләнеш) тора. Тик шул аралашу гына иң шатлыклы, иң борчулы, шул ук вакытта әһәмиятле үткен кичерешләр тудыра. Башка кешеләр белән аралашу күбесенчә шәхеснең әхлакый бәясен билгели.
Безнең уй-фикеребезчә, яхшы кеше ул – билгеле бәйләнешкә сәләтле (яхшы, ачык, ярдәмчел). Башка кешеләргә карата мөнәсәбәт балачакта туа һәм интенсив рәвештә үсә. Кешеләргә булган мөнәсәбәтнең барлыкка килүендә төп мөхит булып яшьтәшләр, тиң кешеләр белән аралашу тора.

Фәнни тикшерүләр күрсәтүе буенча, мәктәпкәчә яшьнең ахырында балаларда яшьтәшләренә карата билгеле бер төрле мөнәсәбәт урнаша, ул норматив аралашуга, килешүгә яисә бәхәсле. авыр аралашуга китереп чыгара. Балалар арасындагы проблемалар, бәхәсләр авыр кичерешләр ( үпкә, көнчелек, усаллык, бер-береңне күрә алмауны) тудыра. Соңыннан бу балаларның кичерешләре олы кешенең эчке яисә җитди аралашу проблемаларының чыганагына әйләнергә мөмкин. Башка кешеләр белән беренче аралашу тәҗрибәсе соңыннан баланың шәхес булып үсешенең нигезе булып тора. Бу беренче тәҗрибә күбесенчә кешенең үззиһенләүенең үзенчәлекләрен, дөньяга карашын, тотышын, кеше арасында үзен хис итүен билгели. Күпчелек башка кешеләр яисә үз –үзе белән булган бәхәсләрнең башлангычы кечкенә балачак белән бәйле.
Балалар арасында килеп чыккан бәхәсләр төрле сәбәпләр аркасында булырга мөмкин: уенда катнашу, катнашмау, уйнаучылар саны аркасында, уенчыклар, уенның сюжеты, кагыйдәсе, уен кагыйдәләре , һ.б.
Балаларның бәхәсләре 2 төрле була: бәхәс-гамәл, бәхәс-сәбәп. Теоретиклар сүзе буенча, бәхәс ике юнәлешле була: эчке һәм тышкы.
Тышкы бәхәсләр балаларда бердәм эшчәнлек һәм аралашу вакытында килеп чыккан каршылыклар аркасында барлыкка килә. Алар вакытлыча, ситуатив характерлы булалар һәм балалар үзләре дөреслек нормативы буенча мөстәкыйль рәвештә чишәләр. Бәхәсләрнең кешеләргә карата файдасы да бар: балалар бәхәсне мөстәкыйль рәвештә чишәргә, үз өсләренә җаваплылык алырга өйрәнәләр, димәк, җаваплылыкка, мөстәкыйль булырга өйрәтә.
Эчке бәхәс күп очракта күзәтү белән генә ачыкланмый. Бу конфликт эшчәнлек белән бәйле, иптәшләренең соравы һәм баланың мөмкинлеге арасында килеп чыккан каршылыклар аркасында барлыкка килә. Эчке каршылыклар зурларсыз чишелми. Алар аркасында баланың эчке дөньясы кысыла, балага шәхес булып формалашуда тискәре йогынты ясый.
Бәхәсне физик көч белән, кайвакыт куркыту, шантаж, көчле басым ясау, үзләренең позицияләрен исбатлау - көч кулланып чишәләр. Бу деструктив ысулга керә.Конструктив ысул белән бәхәсне чишүче балалар – аралашучан, иптәшләре белән дөрес мөнәсәбәттә торучылар. Алар тыныч ысул белән бәхәсне чишә беләләр, бер сүзгә килеп тиз арада аралаша да башлыйлар.

Бәхәсле балаларга – кемнәр керә? Аларны авыр балалар диеп тә әйтәләр. Ул – агрессив , оялчан, демонстратив, үпкәләүчән балалар.